**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 21 сентябрь № 662

г. Казань

«Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында

2016 – 2020 елларга Татарстан Республикасында социаль тармакларны һәм иҗтимагый инфраструктураны үстерү концепциясен тормышка ашыруда катнашу максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль өлкәне һәм иҗтимагый инфраструктураны модернизацияләү һәм үстерү турында» 2016 ел, 3 сентябрь, 614 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

«Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен (карарга теркәлә) расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\662.docx

Татарстан Республикасы
Миистрлар Кабинетының
2016 ел, 21 сентябрь,
662 нче карары белән расланды

**«Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасына (алга таба – Фонд) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия (алга таба – субсидия) бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын регламентлаштыра.

2. Субсидия бирү максаты булып Фонд эшләгән 2016 – 2020 елларга Татарстан Республикасында социаль тармакларны һәм иҗтимагый инфраструктураны үстерү концепциясенең (алга таба – Концепция) Татарстан Республикасы дәүләт программаларында күздә тотылган социаль өлкәне һәм иҗтимагый инфраструктураны модернизацияләү һәм үстерү чараларын Фонд тарафыннан тормышка ашыру тора, шул исәптән Концепциянең максатларына ирешү ихтыяҗыннан чыгып, Фонд тарафыннан фонд рәвешендә төзелә торган коммерциячел булмаган оешмага иректе мөлкәти кертем түләү юлы белән.

3. Субсидия тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына әлеге Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатларга расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

Субсидия күләме Татарстан Республикасы дәүләт программаларының Татарстан Республикасында социаль тармакларны һәм иҗтимагый инфраструктураны үстерү чараларын тормышка ашыруга тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре күләмнәреннән чыгып билгеләнә.

4. Субсидия Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм Фонд арасында төзелә торган килешү (алга таба – килешү) нигезендә бирелә, һәм анда шул исәптән түбәндәге нигезләмәләр карала:

а) субсидия бирү максатлары, шартлары, тәртибе һәм вакытлары, шулай ук финанслар белән тәэмин итү чыганагы агымдагы финанс елында файдаланылмый калган субсидия булган чыгымнарны башкару мөмкинлеге (мөмкин булмавы);

б) субсидия күләме;

в) финанслар белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны җибәрү;

г) Фонд, субсидия алу өчен, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына әлеге Тәртипнең 5 нче пункты нигезендә тапшыра торган документлар исемлеге;

д) финанслар белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны башкару турындагы хисаплылыкны Фонд тарафыннан тапшыру тәртибе, формалары һәм вакытлары;

е) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм дәүләт финанс контроле вәкаләтле органнары үткәргән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча әлеге Тәртиптә һәм килешүдә күздә тотылган субсидия бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен бозу факты ачыкланган очракта, Фонд тарафыннан файдаланылган, финанслар белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган акчаны кайтару тәртибе;

ж) Фондның әлеге Тәртиптә һәм килешүдә күздә тотылган субсидия бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен үтәү буенча йөкләмәсе;

з) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм дәүләт финанс контроле вәкаләтле органнары тарафыннан субсидия бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен үтәүгә тикшерүләр үткәрүгә Фондның ризалыгы;

и) алган субсидия акчасы исәбеннән чит ил валютасы алуны тыю, югары технологияле импорт җиһазлары, чимал һәм комплект тутыру әйберләре сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән, шулай ук әлеге Тәртиптә билгеләнгән башка операцияләрнең күрсәтелгән акчасын бирү максатларына ирешүгә бәйле операцияләрдән тыш;

к) якларның җаваплылыгы.

5. Субсидия Фонд Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы раслый торган форма буенча җитәкчесе тарафыннан имзаланган заявка тапшырганда бирелә.

6. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы:

документлар әйләнеше кагыйдәләре нигезендә кертелгән көнне заявканы терки;

Фондның заявкасын карап тикшерә һәм ул кертелгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә субсидия бирү турында (бирүдән баш тарту хакында) карар кабул итә;

субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә килешүгә кул куя;

субсидия бирүдән баш тарту хакында карар кабул ителгән очракта, әлеге карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә кабул ителгән карар нигезләре күрсәтелә торган хәбәрнамә белән заявканы кире кайтара.

7. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

Фонд тапшырган заявканың әлеге Тәртип таләпләренә туры килмәве;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына билгеләнгән тәртиптә әлеге Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатларга расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары булмавы.

8. Субсидия Фондның кредит оешмасында ачылган хисап счетына килешүдә билгеләнгән вакытларда күчерелә.

9. Фонд Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына килешүдә билгеләнгән формада, тәртиптә һәм вакытларда субсидиядән файдалану турында хисап тапшыра.

10. Килешүдә күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидия Фонд тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр кире кайтарылырга тиеш.

11. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм дәүләт финанс контроле вәкаләтле органнары Фондның субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә Россия Федерациясе законнары нигезендә тикшерүләр үткәрүне гамәлгә ашыра.

12. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм дәүләт финанс контроле вәкаләтле органнары үткәргән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча субсидияләр бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен бозу фактлары ачыкланган очракта, тиешле акча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының тиешле таләбен алган көннән соң 15 көн эчендә Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты керемен кире кайтарылырга тиеш.

13. Әлеге Тәртипнең 10 нчы һәм 12 нче пунктларында күрсәтелгән очракларда, акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемен үз ихтыярлары белән кайтарудан баш тартсалар, акча законнар нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләттерелергә тиеш.

F:\KARAR\2016\662.docx